# Кафил Әмиров ялган сөйли.

“Шәһри Казан” газетасының 2007 ел, 2 ноябрь санында Татарстан Республикасы прокуроры Кафил Әмиров белән “Алтын күргәч, фәрештә дә аза” дип аталган әңгәмә басылып чыккан. Ул анда телефон аша газета укучыларның сорауларына җавап бирә, шул җаваплар арасында минем намусыма кагылганнары да булганга, мин дә газета аша җавап бирергә булдым.

Кафил Әмировка Татарстанда нахакка төрмәләргә утыртылган мљөселманнар турында сорау биргәч, ул: “...Мин үзем бөтен эшләрне җентекләп карадым. “Балигъ булмаган бала да бар гаепләнүчеләр арасында”, - дип шау киләләр. Ул егет, 18 яше тулгач, шушы төркемгә кергән. Шуңа күрә яшүсмерләрне дә җавапка тарталар дигән сүзләр дөрес түгел. Фәүзия Бәйрәмова газета аша халыкка дөрес булмаган мәгълүмат бирде. Без бу хакта аның үзен чакырып сөйләштек, рәсми рәвештә кисәттек. Алга таба да шулай дөрес булмаган дәлилләр белән коткы тараткан очракта, җавапка тартачагыбызны белдердек”, - дип җавап бирә.

Кафил Әмировның бу җавабында ике ялган бар. Беренчесе – гаепләнүчеләр арасында балигъ булмаган яшүсмер бала бар иде, ул – Рөстәм Шәйдуллин. Мин болар хакында узган ел “Шәһри Казан” газетасының 14 ноябрь санында “119468 номерлы эш” дип аталган мәкалә бастырып чыгарган идем. Рөстәм Шәйдуллин 1987 елның 26 февралендә Азнакайда туа, 2004 елның 27 декабрендә аны кулга алалар, 2006 елның августында аны террористлыкта гаепләп, 6 елга иреганнән мәхрүм итәләр. Ягъни, кулга алганда, Рөстәм Шәйдуллинга 17 яшь була, унсигезе исә төрмәдә тула. “Обвинительное заключение”дән күренгәнчә, Рөстәм Шәйдуллин 2001 елдан “Ислам җәмәгате” дип аталган террорристик оешмага кергән, Казанны, Чаллыны, Түбән Каманы шартлатырга уйлаган, ә бит ул вакытта Рөстәмгђә нибары 13 яшь була!

“Таким образом, в 2001 - 2004 годах в г. Набережные Челны, г. Азнакаево РТ Р.И.Шайдуллин принимал участие в разработке с участниками незаконного вооруженного формирования “Исламский джамаат” преступных планов приготовления террористических актов в Республике Татарстан, а именно совершение террористических актов в г. Казани на празднование “Тысячелетия Казани” в августе 2005 года, а также взрывов заводов ОАО “КАМАЗ” в г.Набережные Челны, водозабора в г. Набережные Челны, ОАО “Нижнекамскнефтехим” в г. Нижнекамске, ОАО “Казанского вертолетного завода” в г. Казани в 2007-2008 годах и совершение других террористических актов по указанию полевых командиров Чечни.” (Обвинительное заключение”, 87 бит.)

Ул гына да түгел, балигъ булмаган Рөстәм Шәйдуллин өстендә “Ислам җәмәгате”нең бөтен идеологик пропаганда бурычы да булган икән (88 бит). Һәм иң куркынычы, “Гаепләү акты”ннан күренгәнчә, 13 яшьлек Рөстәм Шәйдуллин ислам дине тотмаган кешеләр белән кулына корал тотып көрәшергә уйлаган! “С 2001 года Р.И.Шайдуллин с целью вооруженной борьбы с лицами, не исповедывающими религию Ислам и не соблюдающие мусульманские религиозные традиции, добровольно вошел в состав незаконного вооруженного формирования “Исламский джамаат” И.Ш.Гумерова.” (Обвинительное заключение”, 96 бит.)

Күрәсез, Кафил Әмиров бу эш белән өстән-өстән генә танышкан, яки белеп тә, дөресен әйтергә теләми. Югыйсә, шул ук “Обвинительное заключение”нең 295нче битендә Рөстәм Шәйдуллинның “җинаять эшләү моментында (нинди җинаять?!”)

балигъ булмавы акка-кара белән язылган бит! “Обстоятельства, смягчающие и отягчающие наказание: Согласно ст.61 УК РФ обстоятельством, смягчающим наказание Р.И.Шайдуллина является его несовершеннолетний возраст на момент совершения преступлений /т. 5, л.д. 128, 130/.”

Мөселман-татар баласы Рөстәм Шәйдуллин бернинди җинаять тә эшләмәде, беркемне үтермәде, үтерергә өндәмәде, Россия империясе каршында аның бар “гаебе” – биш вакыт намаз укуы, Аллаһ кушканча яшәргә омтылуы. Ә андыйларның бу илдә урыны төрмәдә. Хәзер Рөстәм Шәйдуллин Владимир шәһәре төрмәсендә утыра, ә аңа кадәр ул Покров төрмәсендә утырган, анда аны кыйнап, кабыргаларын сындырып бетергәннәр. Аның белән бергә хөкем ителгән татар егете Марат Заһретдинов төрмәдә туберкулез йоктырган, хәзер аны Ерак Көнчыгыш төрмәсенә озатканнар, ялгыз камерага япканнар, ә анда ипи дә күгәрә икән, ә кеше ничек череп үлмәсен! Бу балалар кемнәрнеңдер газизләре бит, нигә алар намаз укыган өчен генә төрмәләрдә череп үләргә тиешләр?!

Кафил Әмиров мине газета укучыларга дөрес булмаган мәгълүмат бирүдә гаепли, ә минем ул язмамда да, монысында да һәр сүзем документлар белән дәлилләнгән, мин һәр сүзем өчен җавап бирергә әзер. Моны Татарстан Республикасы прокуроры үзе дә яхшы белә һәм мәкаләмә каршы җинаять эше кузгатмады. Әмма “Шәһри Казан”га биргән әңгәмәсендә Кафил Әмиров укучыларга дөрес булмаган мәгълүмат җиткерә, “Без Бәйрәмованы чакырып сөйләштек, кисәттек”, ди. Бу хәл булмады, мине бу язмам буенча Чаллы прокуратурасына да, Казанныкына да чакыртмадылар, кисәтмәделәр, ә минем Кафил Әмировны күрмәгәнемә инде ун елдан артык. Дөрес, минем “119468 номерлы эш” дип аталган мәкаләм буенча шул ук “Шәһри Казан” газетасының 2006 ел, 22 ноябрь санында Татарстан Республикасы прокуратурасының матбугат хезмәте һәм РФның Татарстан буенча Федераль иминлек хезмәте идарәсе матбугат хезмәте тарафыннан әзерләнгән белдерү басылып чыкты, алар мине гаепләргә, үзләрен akларга тырышканнар, урысларга каршы сүз әйтмәскә, аларга карата хөрмәтне җимермәскә кушканнар. Ә мөселман-татар ир-атларына, кылмаган җинаятьләр өчен, төрмәләрдә черергә дә ярый икән!

Кафил Әмиров белән әңгәмәнең исеме “Алтын күргәч, фәрештә дә аза”, дип куелган, бу гыйбарә прокурорның җавабыннан алынган. Юк, Кафил әфәнде, фәрештәләр алтын күргәч азмыйлар, чөнки аларда хис-тойгы юк, алар бары тик Аллаһның әмерләрен генә үтәүчеләр. Бу мәкаль үзләренең азгынлыкларын, караклыкларын акларга теләгән ришвәтче түрәләр тарафыннан уйлап чыгарылган. Һәм сез дә татар егетләрен нахакка төрмәләргә утырту белән шөгыльләнгәнче, шушы карак түрәләрне фаш итсәгез, милләт өчен дә, дәүләт өчен дә яхшырак булыр иде!

**Фәүзия Бәйрәмова,**
*язучы, тарих фәннәре кандидаты,*
*“Иттифак” татар милли бәйсезлек партиясе рәисе,*
*Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты әгъзасы.*
2007 ел, 5 ноябрь.